**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**10.12.2015** **№ 01-02/798**

Казан

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау турында

2014 елның 21 июлендәге “Россия Федерациясендә Иҗтимагый контроль нигезләре турында”гы 212-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге “Министрлык, дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында”гы 906 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 15 октябрендәге 856 номерлы, 2013 елның 24 октябрендәге 793 номерлы, 2014 елның 20 сентябрендәге 669 номерлы, 2015 елның 14 маендагы 341 номерлы, 2015 елның 5 сентябрендәге 643 номерлы, 2015 елның 17 ноябрендәге 862 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы әлеге Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 2 мартындагы “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 01-02/147 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урыбасары Р.И.Заһидуллинга йөкләргә.

Министр Л.Ю.Глухова

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
10.12.2016 № 01-02/798
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы
каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба - Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба - Министрлык) каршындагы Татарстан Республикасында гражданнарның хокуклары һәм ирекләрен гамәлгә ашыру һәм иҗтимагый берләшмәләр һәм башка дәүләтнеке булмаган һәм коммерцияле булмаган оешмаларның юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле сорауларны караучы киңәшмә орган булып тора.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм анда керүчеләр саны Министрлык боерыгы белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) таяна.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим характерында була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыра.

1.6. Иҗтимагый совет эшчәнлеге ирекле нигезгә, ачыклык һәм партнерлык принципларына һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына нигезләнә.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара кызыксынулары нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2. Иҗтимагый советның эшчәнлек максатлары һәм бурычлары

2.1. Иҗтимагый советның төп эшчәнлек максатлары булып тора:

гражданнарның ихтыяҗлары һәм кызыксынуларын исәпкә алу, гражданнарның хокуклары һәм ирекләрен һәм иҗтимагый берләшмәләр һәм башка дәүләтнеке булмаган һәм коммерцияле булмаган оешмаларның юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда хокукларын яклау;

Министрлык эшчәнлегенең хәбәрдарлык һәм ачыклык принципларын тормышка ашыру;

Министрлык тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатларына җәмәгать контролен арттыру, юстиция өлкәсендә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары:

юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

норматив хокукый актлар проектларына экспертиза үткәрү;

законда каралган очракларда, Министрлык тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актлар проектлары буенча алдан фикер алышу;

Министрлык тарафыннан карарлар кабул ителгән чакта җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

җәмәгатьчелекне Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча мәгълүматлаштыруны арттыру.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары, аның эшчәнлек нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендәге икътисадый, социаль һәм сәяси ситуацияне исәпкә алып, үзгәртелергә яки тулыландырылырга мөмкин.

## 3. Иҗтимагый советның составы

3.1. Иҗтимагый совет рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм Иҗтимагый советның гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан тәкъдим ителгән әгъзалары составында формалаша. Иҗтимагый советның шәхси составы министр тарафыннан раслана.

3.2. Иҗтимагый совет үз теләге белән катнашучы 10 кеше составында формалаша.

3.3. Иҗтимагый совет составына гражданнар, шул исәптән иҗтимагый оешмалар һәм башка социаль ориентлашкан коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре дә керә ала. Әмма аларның Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр буенча фикер алышуда кирәкле профессиональ сыйфатлары, шул исәптән юридик белемнәре, бу өлкәдәге эш тәҗрибәләре дә исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлардан тыш, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысы санынча Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән затлар да керә.

Иҗтимагый совет составына, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән береннән артмаган санда, элек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларында, Россия Федерациясе дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларында, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларында, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларында, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларында булган затлар да керә ала.

3.4. Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларында, Россия Федерациясе дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфаларында, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларында, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт гражданнар

хезмәте вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларында булучылар, суд карары нигезендә эшкә яраксыз дип табылучы затлар, суд карары нигезендә акланмаган затлар, шулай ук 2005 елның 4 апрелендәге “Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы турында”гы 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы әгъзалары булып тора алмый торган башка затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар.

3.5. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый советның беренче утырышында Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән, әгәр дә алар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы тавыш бирсә, сайлана. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын сайлау турындагы карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен яки рәис урынбасарын вазыйфаларыннан азат итү турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы юстиция министры мөрәҗәгате буенча карала, шулай ук Иҗтимагый совет тарафыннан аларның шәхси гаризалары нигезендә яки Иҗтимагый советның барлык әгъзаларының биштән бер өлеше тәкъдиме буенча карала.

Аның өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы тавыш биргән очракта карар кабул ителгән булып санала.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның тарафыннан Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирелгәндә;

сәламәтлеге буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаса, Иҗтимагый совет эшчәнлегендә катнашудан туктаса яки башка сәбәпләр буенча;

аңа карата чыгарылган суд гаепләү карары законлы көченә кергәндә;

ул эшкә яраксыз дип яки законлы көченә кергән суд карары нигезендә хәбәрсез югалган дип танылганда;

аның тарафыннан этик нормалар дорфа бозылганда - Иҗтимагый советның утырышта катнашкан әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән карары нигезендә;

Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыкканда;

системалы рәвештә (рәттән өч тапкырдан артык) сәбәпсез рәвештә Иҗтимагый совет утырышлары эшендә катнашмаганда;

системалы рәвештә (рәттән ике тапкырдан артык) Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары йөкләмәләрен үтәмәгәндә;

әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларга билгеләнгәндә;

чит дәүләт гражданлыгын алганда.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасы булудан туктау министрның Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яки Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары тарафыннан кергән тәкъдим нигезендә кабул ителгән карары нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында каралган очракларда гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасының сәламәтлеге буенча эшчәнлектә катнаша алмавы, аңа карата чыгарылган суд карары законлы көченә керү, Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу очракларында Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге

фактлар турында Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме белән министр карары нигезендә туктатыла:

ул Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнары тәртибендә җинаять кылуда гаепләнгәндә;

аңа карата административ арест төрендәге административ җәза билгеләнгәндә;

ул дәүләт хакимияте закон чыгару органы депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайлап алына торган вазыйфага кандидат, сәяси партиягә кандидатның вәкаләтле вәкиле яки ышанычлы заты сыйфатында теркәлгәндә, шулай ук Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында референдум уздыру буенча инициатив төркем составына кергәндә.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы хокуклы:

Дәүләт сере, шәхси мәгълүматлар һәм аз кешеләр генә белергә тиешле белешмәләрне туплаган мәгълүматлар кулланылуга бәйле рәвештә аларда катнашу федераль законнар белән чикләнә торган чаралардан тыш, Министрлык инициативасы белән уздырыла торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, “түгәрәк өстәлләр”дә, һ.б.) катнашырга,

инициатива тәртибендә Иҗтимагый советка аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм юлларга;

Иҗтимагый совет рәисе аркылы Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын уздыру тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карар өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырыла торган затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы тиеш:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне үтәргә;

Иҗтимагый советның әлеге Нигезләмәдә каралган эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

үзенә йөкләнгән мәсьәләләрне хәл итү өчен Иҗтимагый совет тарафыннан булдырылган эксперт, эш төркемнәре, комиссияләр, башка эшче органнар эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет утырышларында расланган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Министрлык тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер тапкырдан да кимрәк булмаган санда уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Министрлык башлангычы белән, Министрлык тарафыннан эшләнгән һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнгән, башкарма хакимиятнең әлеге органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан тикшерми торып кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм башка документларның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 мартындагы "Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнгән, башкарма хакимиятнең әлеге органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан тикшерми торып кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм башка документларның составын раслау турында" 214 номерлы карары белән расланган исемлегендә каралган норматив хокукый актларга Иҗтимагый совет йомгаклавын бирү максатында да уздырыла.

5.4. Иҗтимагый совет әгъзалары өчтән ике өлештән дә кимрәк булмаган санда катнашкан очракта Иҗтимагый совет утырышы тулы хокуклы санала. Иҗтимагый совет әгъзасы, утырышта шәхсән катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, бу хакта Иҗтимагый совет рәисен яки рәис урынбасарын яки Иҗтимагый советның җаваплы секретарен алдан кисәтеп, үз тавышын һәм көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз фикерен язмача, факсимиле яки электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына бирү хокукына ия. Иҗтимагый советның утырышта катнашучы әгъзалары санына Иҗтимагый советның үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган әгъзалары да кушыла.

Әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларының (норматив хокукый актлар) Иҗтимагый совет тарафыннан каралышы алар Министрлык тарафыннан Иҗтимагый советка юлланганнан соңгы ун календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Иҗтимагый советның алар буенча йомгаклаулар бирү максатларында тавыш бирү уздыру Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру формасында, сораштыру нәтиҗәләрен беркетмәләштереп һәм Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан, ул булмаганда - Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан имзалап, читтән торып тавыш бирү юлы белән дә гамәлгә ашырыла ала. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки элемтәнең тапшырыла һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең дөреслеген һәм аларның документаль расланышын тәэмин итә торган башка төре аша документлар алмашу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү очрагында, ул уздырылырга 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына тәкъдим ителгән көн тәртибе, шуның буенча Иҗтимагый совет йомгаклавы бирелергә тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары кирәк булган очракта Министрлыктан карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат сорап алалар.

Иҗтимагый совет карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителәләр.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе уздыра, ул булмаганда - Иҗтимагый совет рәисе урынбасары.

5.6. Иҗтимагый советның аңа йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләр нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим характерында була һәм кызыксынган затлар игътибарына Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яки Иҗтимагый совет карары нигезендә башка юл белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыклар сайтында “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет” өстәмә битендә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет күрсәтмәләрен, Иҗтимагый совет беркетмәләрен һәм башка документларын имзалый;

Иҗтимагый совет утырышларын уздыру урынын һәм вакытын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән бурычлар һәм максатлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән таләпләр, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләр имзалый;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе булмаганда аның вазыйфаларын башкара;

Иҗтимагый совет утырышларына әзерлекне гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисе раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре:

утырышларга материаллар һәм карар проектлары әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышы булачак урын һәм вакыт, көн тәртибе турында белдерә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет һәм Министрлыкның оештырылыш хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлегенең документаль-техник тәэмин ителешен гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның гамәлгә ашырылышын тикшерүдә тота;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңлау һәм фикер алышуга сораулар әзерләү өчен эш, эксперт төркемнәренә һәм башка эш органнарына берләшә, Иҗтимагый совет рәисе белән килештерү нигезендә, материаллар әзерләүгә Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне җәлеп итә алалар.

5.12. Иҗтимагый совет карары белән Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет карый торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм нәтиҗәләр ясау өчен башкарма органнар, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырыла ала. Массакүләм мәгълүмат чараларының Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаучы вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнаша алалар.

5.13. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар Иҗтимагый советның шушы мәсьәләләр каралачак утырышы билгеләнгән көнгә кадәрге ун календарь көннән дә соңга калмыйча Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны билгеләнгән вакыттан соңгарак калып тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яки аның урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең техник һәм оештырылыш ягын Министрлык тәэмин итә.